КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 сентябрь г.Казань № 743

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 апрель, 285 нче; 2014 ел, 11 октябрь, 753 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1084 нче; 2015 ел, 31 декабрь, 1037 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1049 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1094 нче; 2018 ел, 13 июль, 570 нче һәм 2018 ел, 27 декабрь, 245 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программа исемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа паспорты

<table>
<tr><td>Программа исеме</td><td>2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү (алга таба – Программа)</td></tr>
<tr><td>Программаның дәүләт заказчысы</td><td>Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүче</td><td>Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td>Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән нәтиҗәле идарә итү</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td>Бюджет системасының озак вакытка балансланган булуын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү;<br>дәүләт бурычлары белән нәтиҗәле идарә итү;<br>җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеген күтәрү</td></tr>
<tr><td>Программаны тор-мышка ашыру вакыт-лары</td><td>2014 – 2024 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганак-лар буенча бүлеп, Программаны фи-нанслау күләмнәре</td><td>2014 – 2024 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 118 040 286,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме, мең сум</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>10 667 262,8</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>8 964 802,1</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>10 551 579,9</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>11 186 510,1</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>13 547 784,5</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>11 215 853,1</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>10 116 526,7</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>9 846 141,9</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>10 239 987,6</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>10 644 573,1</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>11 059 264,6</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>118 040 286,4</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычларын һәм максатларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)</td><td>Программаны тормышка ашыру вакыты ахырына түбәндәгеләргә ирешү планлаштырыла:<br>Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми еллык күләменә карата (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгының бюджет керемнәреннән (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча) һәм</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | бюджет чыгымнарыннан (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны исәпкә алмыйча) чыгып хисапланган мөнәсәбәтен 2,5 проценттан да артмаган күләмдә тәэмин итүгә;<br>Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә программалар кысаларында формалаштырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының чагыштырма авырлыгын (субвенцияләрне исәпкә алмыйча) 84 процентка кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны исәпкә алмыйча) Татарстан Республикасы бюджетының капиталь характердагы чыгымнары өлешен (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган капиталь характердагы чыгымнарны исәпкә алмыйча) кимендә 11 процент дәрәҗәсендә тәэмин итүгә;<br>алдагы ел дәрәҗәсенә карата Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләме темпы кимендә 101,9 процентка артуга;<br>Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләмен 242,9 млрд.сумга кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләмен 291,0 млрд.сумга кадәр арттыруга;<br>хисап финанс елында Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми еллык күләменә карата хисап елыннан соң килүче елның 1 гыйнвары хәленә булган Татарстан Республикасы дәүләт бурычлары күләме мөнәсәбәте мәгънәсен (кире кайтарылмый торган керемнәр күләмнәрен исәпкә алмыйча) 31,2 процenttан артмаган дәрәҗәдә тәэмин итүгә;<br>чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда җирле бюджетларның беркетелгән керем чыганаклары һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар мөнәсәбәтләрен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә чыгымнарның кирәкле күләменә карата кимендә 100 процент дәрәҗәсендә тәэмин итүгә»; |

Программаның 2 бүлегендә:

егерме өченче абзацта «2,6 проценттан артмаган» сүзләрен «2,5 проценттан артмаган» сүзләренә алыштырырга;

егерме алтынчы абзацта «кимендә 103,2 процент» сүзләрен «кимендә 101,9 процент» сүзләренә алыштырырга;

егерме җиденче абзацта «217,3 млрд.сумга кадәр» сүзләрен 242,9 млрд.сумга кадәр» сүзләренә алыштырырга;

егерме сигезенче абзацта «263,1 млрд.сумга кадәр» сүзләрен «291,0 млрд.сумга кадәр» сүзләренә алыштырырга;

егерме тугызынчы абзацта «42,6 проценттан артмаган» сүзләрен «31,2 проценттан артмаган» сүзләренә алыштырырга;

утыз беренче абзацта «2014 – 2021 еллар» сүзләрен «2014 – 2024 еллар» сүзләренә алыштырырга;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2014 – 2024 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 118 040 286,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елга – 10 667 262,8 мең сум;
2015 елга – 8 964 802,1 мең сум;
2016 елга – 10 551 579,9 мең сум;
2017 елга – 11 186 510,1 мең сум;
2018 елга – 13 547 784,5 мең сум;
2019 елга – 11 215 853,1 мең сум;
2020 елга – 10 116 526,7 мең сум;
2021 елга – 9 846 141,9 мең сум.
2022 елга – 10 239 987,6 мең сум;
2023 елга – 10 644 573,1 мең сум;
2024 елга – 11 059 264,6 мең сум.

Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аңа, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаның исемендә һәм нумерация башисемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«2014 – 2024 елларга Татарстан
Республикасының дәүләт финанслары белән
идарә итү» дәүләт программасына
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 2 сентябрь, 743 нче
карары редакциясендә)

## «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасы максаты, бурычлары, аның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау

| Максат исеме | Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Үтәү вакыты | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау, мең сум | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2013 (база) ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
| Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән нәтиҗәле идарә итү | Бюджет системасының озак вакытка балансланганлыгын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү | | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – ТР Финанс министрлыгы) | 2014 – 2024 еллар | Татарстан Республикасы бюджетының гомуми еллык керемнәре күләменә карата (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча) бюджет керемнәреннән чыгып (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәрне исәпкә алмыйча) һәм бюджет чыгымнарына (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр исәбеннән гамәлгә ашырылучы чыгымнарны исәпкә алмыйча) хисаплап чыгарылган Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы мөнәсәбәте, процент | 0,2 | 13,4 | 6,2 | 4,1 | 0,1 | 3,9 | 1,9 | 2,3 | 2,6 | 2,5 | 2,5 | 2,5 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә программалар кысаларында формалаштырыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының чагыштырма авырлыгы (субвенцияләрне исәпкә алмыйча), процент | 75,0 | 76,0 | 78,0 | 79,0 | 90,0 | 90,0 | 89,0 | 86,0 | 84,0 | 84,0 | 84,0 | 84,0 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә (бюджет системасының башка бюд- | 15,8 | 14,5 | 9,0 | 6,5 | 5,0 | 9,0 | 9,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 | 11,0 | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | жетларыннан максатчан характердагы кире кай-тарылмый торган керемнәр исәбенә гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны исәпкә алмыйча) капиталь характердагы Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары өлеше (бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан характердагы кире кайтарылмый торган керемнәр исәбенә гамәлгә ашырыла торган капиталь характердагы чыгымнарны исәпкә алмыйча), процент | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | Узган ел дәрәҗәсенә карата Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләме арту темпы, процент | 102,1 | 111,8 | 110,9 | 109,8 | 108,0 | 106,9 | 97,5 | 100,9 | 102,0 | 100,0 | 100,9 | 101,9 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләме, млрд.сум | 130,5 | 145,9 | 167,3 | 186,6 | 207,1 | 228,5 | 229,3 | 231,3 | 236,0 | 236,1 | 238,3 | 242,9 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләме, млрд.сум | 168,3 | 180,5 | 205,4 | 227,5 | 250,0 | 273,0 | 273,1 | 275,5 | 280,4 | 281,7 | 285,1 | 291,0 | | | | | | | | | | | |
| | | Бюджет системасы тотрыклылыгын саклауны тәэмин итә торган бюджет проектын эшләү һәм Татарстан Республикасы бюджетын үтәү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Расланган дәрәҗәгә карата чыгымнар буенча Татарстан Республикасы бюджетын үтәү (бюджетара трансфертлар һәм капиталь характердагы чыгымнар исәбеннән тотыла торган чыгымнарны исәпкә алмыйча), процент | 99,5 | 99,6 | 99,7 | 99,0 | 98,0 | 97,0 | 98,0 | 98,0 | 98,0 | 98,0 | 98,0 | 98,0 | 602 709,8 | 611 855,9 | 662 108,1 | 697 660,9 | 827 646,0 | 629 356,9 | 599 007,4 | 600 375,6 | 603 977,6 | 628 136,7 | 653 262,2 |
| | | | | | Расланган дәрәҗәгә карата салым һәм салым булмаган керемнәр буенча Татарстан Республикасы бюджетын үтәү, процент | 102,6 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары күләменә карата Татарстан Республикасының кичектерелгән кредиторлык бурычлары күләме мөнәсәбәте, процент | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләменә карата Татарстан Республикасы бюджетының тикшерелгән акчасы күләме мөнәсәбәте, процент | 7,2 | 7,5 | 7,8 | 7,9 | 8,0 | 8,1 | 8,2 | 8,2 | 8,2 | 8,3 | 8,3 | 8,3 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | | | | Хисап чорында бюджет законнарын бозуларның ачыкланган фактлары гомуми санына карата (хисап чоры ахырында ачыкланган һәм алар буенча карарлар кыләсе хисап чорында кабул ителәчәк закон бозу фактларыннан тыш) Татарстан Респуб- | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ликасы бюджеты акчасының ничек сарыф ителүенә тикшерүләр үткәрү барышында ачыкланган бюджет законнарын бозу фактлары буенча кабул ителгән карарлар саны мөнәсәбәте, процент | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру һәм бюджет хисаплылыгын төзү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Хисап елында Татартан Республикасы бюджетын үтәү турында еллык хисап төзүнең билгеләнгән тәртибен һәм аны Федераль казначылыкка кертү вакытын үтәү, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | Дәүләт бурычлары белән нәтиҗәле идарә итү | | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Хисап финанс елында Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми еллык күләменә хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт бурычы күләменә мөнәсәбәте (кире кайтарылмый торган керемнәр күләмнәрен исәпкә алмыйча), процент | 65,35 | 68,3 | 54,6 | 51,7 | 47,0 | 42,1 | 45,3 | 44,5 | 42,6 | 38,7 | 35,0 | 31,2 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 гыйнвар, б-10 нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт бурычлары күләмен Татарстан Республикасы дәүләт бурычларының иң чик күләмнәреннән артмаган күләмдә саклауны тәэмин итү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Хисап елыннын соң килүче елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасы дәүләт бурычлары күләме, млрд.сум | 85,3 | 99,5 | 91,3 | 96,4 | 96,4 | 96,1 | 94,2 | 93,6 | 92,5 | 91,3 | 83,5 | 75,7 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | | | | Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлар күләме, млрд.сум | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы дәүләт бурычларына хезмәт күрсәтү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт бурычларына хезмәт күрсәтүгә чыгымнар өлеше, процент | 0,20 | 0,23 | 0,04 | 0,04 | 0,03 | 0,03 | 0,04 | 0,04 | 0,04 | 0,03 | 0,03 | 0,03 | 350 032,2 | 87 439,3 | 86 330,7 | 76 585,5 | 84 846,1 | 89 490,3 | 89 166,8 | 88 558,4 | 82 480,6 | 80 765,8 | 72 905,0 |
| | | Бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясе алдындагы бурычлары | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясе алдындагы бурычлары структурасын үзгәртүнең үтәлгән шартлары өлеше, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | структурасын үзгәртү шартлары үтәлешен тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | Җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәлелеген күтәрү | | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен чыгымнарның кирәкле күләменә карата җирле бюджетларның беркетелгән керемнәр чыганаклары һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар мөнәсәбәте, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | | Муниципаль берәмлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бирү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджетлар белән бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының бюджет тәэмин ителешен тигезләгәннән соң иң аз тәэмин ителгән һәм иң күп тәэмин ителгән биш муниципаль район (шәһәр округы) буенча исәп-хисап бюджет тәэмин ителешләренең уртача дәрәҗәләре чагыштырмасы, тапкыр | 1,014 | 1,1 | 1,1 | 1,1 | 1,09 | 1,09 | 1,08 | 1,08 | 1,08 | 1,08 | 1,08 | 1,08 | 264 287,7 | 326 152,1 | 1 234 292,7 | 389 083,1 | 750 443,3 | 752 231,0 | 674 184,7 | 535 536,9 | 556 958,4 | 579 236,7 | 602 406,2 |
| | | Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә һәм бюджетара трансфертларның башка төрләрен бирүгә муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр бирү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Субсидияләрнең күрсәтелгән төре гомуми күләмендә муниципаль район составына керә торган җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирүгә һәм бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль районнар бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан үз вакытында һәм тулы күләмдә бирелгән субсидияләрнең чагыштырма авырлыгы, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 1 167 982,2 | 1 169 241,6 | 1 397 666,3 | 1 352 319,8 | 1 320 867,2 | 1 481 702,5 | 1 461 400,9 | 1 358 519,4 | 1 412 860,2 | 1 469 374,6 | 1 528 149,6 |
| | | Муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Муниципаль белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренә эш хакы буенча кичектерелгән кредиторлык бурычлары күләме, мең сум | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 8 265 973,1 | 6 677 595,4 | 7 065 899,5 | 8 598 689,8 | 10 506 942,2 | 8 144 198,5 | 7 193 089,3 | 7 195 794,5 | 7 513 659,4 | 7 814 205,8 | 8 126 774,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруга, муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруга, балаларны караштырып тору һәм карау, балаларны муниципаль белем бирү оешмаларында тәрбияләп тору өчен шартлар тудыруга, шулай ук каникуллар вакытында балалар ялын оештыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү | | | Мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә финанс нормативларын билгеләү буенча муниципаль норматив базаны кабул итү һәм аларны, капиталь характердагы чыгымнардан һәм максатчан чыгымнардан тыш, җирле бюджетлар чыгымнарын планлаштырганда куллану, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр бирү | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Субвенцияләрнең түбәндәге төренең гомуми күләмендә җирлекләргә финанс ярдәме күрсәтү төбәк фондыннан җирлекләргә дотацияләр хисаплау һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга муниципаль районнар бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан үз вакытында һәм тулы күләмдә бирелгән субвенцияләрнең чагыш-тырма авырлыгы, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 16 277,8 | 92 517,8 | 105 282,6 | 72 171,0 | 57 039,7 | 118 873,9 | 99 677,6 | 67 357,1 | 70 051,4 | 72 853,5 | 75 767,6 |
| | | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре финанслары белән | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Финанслар белән идарә итү сыйфатын һәм түләү сәләтен мониторинглауның үтәлгән күрсәткечләренең муниципаль берәмлекләр буенча уртача өлеше, процент | 75,0 | 75,0 | 75,5 | 76,0 | 76,5 | 77,0 | 77,5 | 78,0 | 78,5 | 79,0 | 79,5 | 80,0 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | идар итү сыйфатын ел (квартал) саен оператив бәяләү турында» 2008 ел, 11 июнь, 07-61 нче боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанслар белән идарә итү сыйфатын һәм түләү сәләтен мониторинглау | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | Бюджет акчасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җирле бюджетларның салым һәм салым булмаган кеременнән акча керүне арттыру чаралары турында муниципаль берәмлекләр белән килешүләр төзү һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру | ТР Финанс министрлыгы | 2014 – 2024 еллар | Бюджетларында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар өлеше (төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлардан һәм субвенцияләрдән тыш) һәм (яки) соңгы өч хисап финанс елының икесе эчендә тотып калына торган өстәмә норматив акча белән алыштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәп-хисап күләменнән артмаган күләмдә тотып калына торган акчаның өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре җирле бюджетларның үз керемнәре күләменең 50 процентыннан артык булган муниципаль берәмлекләренең гомуми күләмендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән бюджет акчасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җирле бюджетларның салым һәм салым булмаган керемнәре акчасын арттыру чаралары турында килешүләр төзегән муниципаль берәмлекләр өлеше, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Җирле бюджетларның салым һәм салым булмаган керемнәреннән акча керүне арттыру һәм бюджет акчасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турындагы килешүләрне үтәү хакындагы хисапларның гомуми санында Татарстан Республикасы муниципаль районнары үз вакытында керткән хисаплар өлеше, процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | | | | | | | | | | | |
| **Программа буенча барлыгы** | | | | | | | | | | | | | | | | | | **10 667 262,8** | **8 964 802,1** | **10 551 579,9** | **11 186 510,1** | **13 547 784,5** | **11 215 853,1** | **10 116 526,7** | **9 846 141,9** | **10 239 987,6** | **10 644 573,1** | **11 059 264,6** |